СОВЕТ ЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.9, с. Нижние Яки
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422157

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа ур., 9 нче йорт, Түбән Яке авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422157

тел.(факс): (85563) 2-94-38; e-mail: Yak.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение　　　　　　　　　　Карар

«20 »февраль 2023 ел　　　　　　　　№ 2-21

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 июнендәге 1-34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ, «Территорияләрнең комплекслы үсешен тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №494-ФЗ федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмешкүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Яке авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 июнендәге 1-34 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмешкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Җәмәгать тыңлауларын (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»1-34 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 12 статьясындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, шәһәр округларының генераль планнары (алга таба әлеге статьяда - иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар) буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3 пунктының 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 3.1 һәм 3.2 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге башлыгы Низаметдинов Р.К.йөкләргә.

яке авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы Р.К.Низаметдинов